**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Лесная ур., 2 йорт

**СОВЕТ АКТАНЫШБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740, село Актаныш, ул. Лесная, дом 2

---

**РЕШЕНИЕ**
**16 август 2021 ел**

**КАРАР**
**№ 19**

Татарстан Республикасы  Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеген җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Актанышбаш Муниципаль берәмлек уставы нигезендә, Татарстан Республикасы  Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеген Советы

Карар бирә:

1. 17.12.2013 ел №18 Совет карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеген муниципаль берәмлекнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә,:

1) "шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналар. 35.1. түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен " рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең минималь күләме-1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 5000 кв. м.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актанышбаш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Актанышбаш авыл җирлеге Советы Рәисе Х.М.Хакимов